**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан шәһәре **БОЕРЫК**

_06.05.2021_ ___513-п__

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 13 апрелендәге 481-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2020 елның 13 апрелендәге 481-п номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәдуллинга йөкләргә.»

2. Боерык белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Исемлек, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлык белән килешү буенча, Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның 2020 елның 6 октябрендәге 428 номерлы боерыгы белән расланган тәртиптә Министрлык тарафыннан раслана.»;

7.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5. Аукцион үтмәгән дип танылa, әгәр дә:

а) Аукционда катнашу өчен гаризалар булмаса;

б) гариза бирүчеләрнең берсе дә Аукционда катнашуга кертелмәгән булса;

в) Аукционда катнашуга бары тик бер генә гариза бирүче кертелгән булса;

г) Аукцион комиссиясенең йомгаклау утырышында бары тик бер генә гариза бирүче катнашса яки гариза бирүчеләр катнашмаса;

д) Аукционда катнашучылар тарафыннан старт күләменнән зуррак дәрәҗәдә бер тапкыр бирелә торган түләү тәкъдим ителмәсә;

е) Аукционда җиңүче җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тарту турында белдерсә;

ж) Аукцион үткәрү барышында әлеге Аукцион шартларын җитди бозылса;

з) Аукционда катнашу өчен гаризалар тапшыру срогы тәмамлангач бер генә гариза тапшырылган булса һәм мондый гариза әлеге Нигезләмәнең таләпләренә һәм Аукцион шартларына туры килә дип танылса.»;

7.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6. Әгәр Аукцион әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктындагы «а»-«ж» пунктчаларында каралган нигезләр буенча узмаган дип танылса, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирелми.

Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

Яңа Аукцион үткәрү турында белдерү әлеге Нигезләмәнең 4.7 һәм 4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына Аукцион әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктындагы «з» пунктчасында каралган нигез буенча узмаган дип танылса, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы Аукционда бердәнбер катнашучыга Аукцион шартларында, җир асты байлыклары турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә, ул бер тапкыр түләнә торган түләүнең Аукционның бер адымына туры килә торган калган өлешен һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы түләгәч бирелә.

Әгәр электрон мәйданчык операторы тарафыннан электрон мәйданчыкта лицензия проекты һәм лицензия килешүе урнаштырылган датадан соң 10 эш көне эчендә Аукционның бердәнбер катнашучысы Аукционны оештыручыга әлеге документларның имзаланган проектларын тапшырмаса һәм Аукцион уздырылуы турындагы белдерүдә күрсәтелгән счетка бер тапкыр түләнергә тиешле сумманың калган өлешен күчермәсә һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләмәсә, Министрлык җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.»;

7.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.8. Әгәр электрон мәйданчык операторы тарафыннан электрон мәйданчыкта лицензия проекты һәм җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турындагы лицензия килешүе урнаштырылган датадан соң 10 эш көне эчендә Аукционның бердәнбер катнашучысы Министрлыкка әлеге документларның имзаланган проектларын тапшырмаса һәм Аукцион уздырылуы турындагы белдерүдә күрсә-телгән счетка бер тапкыр түләнергә тиешле сумманың калган өлешен күчермәсә һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын түләмәсә, Министрлык Аукцион нәтиҗәләрен һәм җирле

әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.».

3. Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукцион үткәрүнең типлаштырылган тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.1. Аукцион үтмәгән дип таныла, әгәр:

а) Аукционда катнашу өчен гаризалар булмаса;

б) гариза бирүчеләрнең берсе дә Аукционда катнашуга кертелмәгән булса;

в) Аукционда катнашуга бары тик бер генә гариза бирүче кертелгән булса;

г) Аукцион комиссиясенең йомгаклау утырышында бары тик бер генә гариза бирүче катнашса яки гариза бирүчеләр катнашмаса;

д) Аукционда катнашучылар тарафыннан старт күләменнән зуррак дәрәҗәдә бер тапкыр бирелә торган түләү тәкъдим ителмәсә;

е) Аукционда җиңүче җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукыннан язма рәвештә баш тарту турында белдерсә;

ж) Аукцион үткәрү барышында әлеге Аукцион шартларын җитди бозылса;

з) Аукционда катнашу өчен гаризалар тапшыру срогы тәмамлангач бер генә гариза тапшырылган булса һәм мондый гариза әлеге Нигезләмәнең таләпләренә һәм Аукцион шартларына туры килә дип танылса.»;

11.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.2. Әгәр Аукцион әлеге Типлаштырылган тәртипнең 11.1 пунктындагы «а»-«ж» пунктчаларында каралган нигезләр буенча узмаган дип танылса, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия бирелми.

Аукционны гамәлдә булмаган дип тану турында карар Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры боерыгы белән раслана.

Яңа Аукцион үткәрү турында белдерү Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнарны әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәнең 4.7 һәм 4.8 пунктларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукына Аукцион әлеге Типлаштырылган тәртипнең 11.1 пунктындагы «з» пунктчасында каралган нигез буенча узмаган дип танылса, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы Аукционда бердәнбер катнашучыга Аукцион шартларында, җир асты байлыклары турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә, ул бер тапкыр түләнә торган түләүнең Аукционның бер адымына туры килә торган калган өлешен һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасы түләгәч бирелә.

Әгәр электрон мәйданчык операторы тарафыннан электрон мәйданчыкта лицензия проекты һәм лицензия килешүе урнаштырылган датадан соң 10 эш көне эчендә Аукционның бердәнбер катнашучысы Аукционны оештыручыга әлеге документларның имзаланган проектларын тапшырмаса һәм Аукцион уздырылуы турындагы белдерүдә күрсәтелгән счетка бер тапкыр түләнергә тиешле сумманың калган өлешен күчермәсә һәм лицензия биргән өчен дәүләт пошлинасын

түләмәсә, Министрлык җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турындагы карарны гамәлдән чыгару турында карар кабул итә.».

4. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

Министр А.В. Шадриков